**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 17 апрель № 261

г. Казань

2015 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында» 2011 ел, 5 июль, 538 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2015 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативын 172,69 сум күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\261.doc